# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АНТОНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

№ 84-4 28.01.2020ел.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Антоновка авыл җирлеге Советының 2013 елның 1 июль 40-1 номерлы карары белән расланган Спас муниципаль районының Антоновка авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (2016 елның 28 октябрендәге 18-1нче номерлы, 2019 елның 22 апрелендәге 62-2 нче номерлы, 2019 елның 16 сентябрендәге 73-2 нче номерлы үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 472-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Антоновка авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Антоновка авыл җирлеге Советының 2013 елның 1 июль 40-1 номерлы карары белән расланган Спас муниципаль районының Антоновка авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (2016 елның 28 октябрендәге 18-1нче номерлы, 2019 елның 22 апрелендәге 62-2 нче номерлы, 2019 елның 16 сентябрендәге 73-2 нче номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Кагыйдәләрнең 14 статьясында:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Куллануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы гариза "Электрон имза турында" 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - электрон имза белән имзаланган электрон документ) таләпләре нигезендә электрон имза рәвешендә җибәрелергә мөмкин."

б) 4 өлештә «ун көн» сүзләрен «җиде эш көне» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Кагыйдәләрнең 15 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацында түбәндәге эчтәлекле яңа җөмлә өстәргә: «Рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турындагы гариза электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин.».

1.3. Кагыйдәләрнең 26 статьясында:

а) 7 өлешнең 4 нче абзацында «ундүрт көн» сүзләрен «җиде эш көне» сүзләренә алмаштырырга.

б) 5 өлештә «территорияне ызанлау проекты» сүзләреннән соң «яисә әлеге статьяның 5 пунктындагы пунктчада каралган очракта территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында карар» сүзләрен өстәргә.

в) түбәндәге эчтәлекле а һәм б пунктлар өстәргә:

«а). Федераль әһәмияттәге линия объектын, региональ әһәмияттәге линия объектын яисә җирле әһәмияттәге линия объектын төзү, реконструкцияләүне күздә тоткан территорияне планлаштыру документларын раслаганчы гамәлгә ашырылырга мөмкин. Бу очракта төзүче яисә техник заказчы биремнәнә мәҗбүри кушымталар булып проектлау санала:

1) территорияне планлаштыру буенча шундый документлар әзерләү турында карар;

2) тиешле линия объектын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләре сызыгы, аның характеристикалары турында белешмәләр һәм планлаштыру хәл ителешләре схемасы, тиешле линия объекты территориясен планлаштыру документларында каралган.

б). Әлеге статьяның 5 пунктында каралган очракта, линия объектының проект документациясе линия объектын төзүне, реконструкцияләүне күздә тоткан территорияне планлаштыруның расланган проекты булган очракта проект документациясенә экспертизага җибәрелә.».

1.4. Кагыйдәләрнең 27 статьясындагы 7 өлешендә «төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза алган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.5. Кагыйдәләрнең 29 статьясында:

а) 29 статьяның 1 өлешендәге 3 абзацына түбәндәге эчтәлекле яңа җөмлә өстәргә: «Исемнәрендә «махсуслаштырылган төзүче» сүзләре булган төзүчеләр, шулай ук күрсәтелгән гариза белән торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасыннан файдаланып мөрәҗәгать итә алалар, моңа Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты нигезендә объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасы белән интеграцияләнергә тиешле башка мәгълүмат системалары аша гамәлгә ашырылган очраклар керми.».

б) түбәндәге эчтәлекле 3.1 өлеш өстәргә:

«3.1. Башкарма комитет капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү этапларына карата күрсәтелгән рөхсәтләрне Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 12 өлешендә һәм 52 статьясындагы 3 өлешендә каралган очракларда бирә»;

в) түбәндәге эчтәлекле 3.2 өлеш өстәргә:

«3.2. Капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү этабына карата объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 3 өлешенең 4, 6-12 пунктларында күрсәтелгән документлар капиталь төзелеш объектын төзүнең, реконструкцияләүнең тиешле этабына караган өлешендә рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән очракта капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү этабына карата объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү турындагы гаризада капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү этабына (булган очракта) карата элек тапшырылган рөхсәт кәгазе күрсәтелә."

г) 4 өлештә «җиде эш көне дәвамында» сүзләрен «биш эш көне дәвамында» сүзләренә алмаштырырга.

д) 4 өлешкә түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бирелә, объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү турындагы гаризада күрсәтелгән очракта.».

2. Әлеге карарны Антоновка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru), һәм хокукый мәгълүмат сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Авыл җирлеге башлыгы Антоновка В.С.Фролов